УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Федосеевская, 36, г. Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ
Федосеев ур., 36, Казан шәһәре, 420111

Телефон, факс (843) 221-77-85, сайт: www.gtn.tatarstan.ru, эл.почта: gostehnadzorrt@mail.ru

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

«07» 05 2020 ел. № 01-05/47-пр

Казан шәһәре

Теркәү турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесен биреп, аттракционнарны теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1064 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турында нигезләмә нигезендә,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Теркәү турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесен биреп, аттракционнарны теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Теркәү, автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу һәм махсус эш секторына әлеге регламентны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту өчен үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык Р. Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең
07.05.2020 № 01-05/47-пр.
боерыгы белән расланды

**Теркәү турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесен биреп, аттракционнарны теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Теркәү турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесен биреп, аттракционнарны теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Административ регламент) Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе) дәүләт хезмәте күрсәткәндә административ процедураларының һәм административ гамәлләренең вакытларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: файдаланучы затлар – законлы нигезләрдә аттракционны эшләтүче һәм күңел ачу хезмәтләрен күрсәтү өчен аттракционнан файдаланучы юридик затлар яки шәхси эшкуар сыйфатында теркәлгән физик затлар.

Мөрәҗәгать итүче исеменнән закон нигезендә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкил дә эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе), Идарәнең территориаль бүлекләре (алга таба – Идарә бүлеге, баш дәүләт инженер-инспекторы, вазыйфаи зат) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев урамы, 36 йорт.

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 8.00 башлап 17.00 кадәр, җомга: 8.00 башлап 15.45 кадәр, төшке аш: 12.00 башлап 12.45 кадәр.

Җәмәгать транспортында «Батурин» тукталышына кадәр килергә кирәк:

- 22, 28, 89 номерлы автобуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе бүлекләренең урнашу урыннары, белешмә телефоннары, электрон почта адреслары Регламентка кушымтада (белешмәлектә) күрсәтелгән.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең һәм Идарә бүлекләренең эш сәгатьләрендә.

1.3.2. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе телефоннары: 8 (843) 221-77-85, 221-77-89. Факс: 8 (843) 221-77-85.

1.3.3. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://gtn.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә Идарә бүлекләренең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында (http://gtn.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru);

3) Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм Идарә бүлекләренә телдән (шәхсән яисә телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм Идарә бүлекләренә язмача (шул исәптән электрон документ формасында да) мөрәҗәгать иткәндә (электрон адреслар Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән).

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә (алга таба – күпфункцияле үзәк) һәм күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарына мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарының урнашкан урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турында белешмәләрне үз эченә ала;

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Салым кодексы (алга таба – РФ Салым кодексы);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе

законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон);

«Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) һәм дәүләт хакимияте башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, №42, 5005 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №15, 2036 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Россия Федерациясе Президенты указы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №19, 2338 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр һәм федераль башкарма хакимият органнары, бюджетка карамаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек итү турында» 2011 елның 27 сентябрендәге 797 номерлы карары (алга таба – 797 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №40, 5559 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәҗбүри сертификатлаштырылырга тиешле продукциянең бердәм исемлеген һәм ярашлылыгын раслау декларация кабул итү рәвешендә гамәлгә ашырыла торган продукциянең бердәм исемлеген раслау турында» 2009 елның 1 декабрендәге 982 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, №50, 6096 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аттракционнарның техник торышына һәм аларны эшләтүгә карата таләпләр раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 1732 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2019, №52 (I өлеш), 7972 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аттракционнарны дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1939 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2020, № 2 (II өлеш), 184 статья (алга таба – Кагыйдәләр).

Евразия икътисадый комиссиясенең «Евразия икътисадый берлегенең «Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында»гы техник регламентының көчмә нигезләмәләре турында» 2017 елның 28 февралендәге 25 номерлы карары (Евразия икътисадый берлегенең рәсми сайты http://www.eaeunion.org/, 2017, 2

март);

Евразия икътисадый берлегенең «Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында»гы техник регламенты (ТР ЕАЭС 038/2016) (Евразия икътисадый комиссиясе советының 2016 елның 18 октябрендәге 114 номерлы карары белән кабул ителгән) (Евразия икътисадый берлегенең рәсми сайты http://www.eaeunion.org/, 2016, 23 декабрь)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, №46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турында» 2011 елның 26 декабрендәге 1064 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 03.02.2012, №9, 0321статья) (алга таба – Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе турында нигезләмә, 1064 номерлы ТР МК карары);

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

авария – аттракционның яки аның кешеләрнең гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыра торган яки кеше гомеренә яки сәламәтлегенә зыян салган кискен компонентының җимерелүе;

автодром һәм картинг – киртәләп алынган (чикләнелгән) киңлектә пассажир модульләре хәрәкәт юнәлешләреннән тыш ирекле рәвештә хәрәкәт итә ала торган аттракционнар;

механикалаштырылмаган су аттракционы – аквапарклар, бассейннар һәм сулыклар өчен су кулланыла торган аттракцион;

балалар аттракционы – (90 см башлап 160 см кадәрге) балаларга күңел ачу өчен махсус проектланган аттракцион;

механикалаштырылган аттракцион – билгеләнгән траектория буенча яки чикләнгән киңлек чикләрендә, төрле төрдәге энергиядән файдалану юлы белән, мускул энергиясеннән тыш, пассажирлар йөртүче аттракцион;

әйләнгеч хәрәкәтләр ясый торган механикалаштырылган аттракцион – башлыча әйләндереп (әйләндерү һәм (яки) чайкалдыру юлы белән), шул исәптән катлаулы хәрәкәтләр ясап, пассажир модульләрен күчереп йөртә торган аттракцион;

алга таба хәрәкәт итүче механикалаштырылган аттракцион – юнәлешләрендә башлыча алга таба хәрәкәт итеп, пассажир модульләрен бер урыннан икенче урынга күчә торган аттракцион;

катлаулы хәрәкәтләр ясый торган механикалаштырылган аттракцион – катлаулы траектория буенча яки пассажирлар күрсәткән сурәтләр белән

бәйләнештә пассажир модульләрен бер урыннан икенче урынга күчерә торган аттракцион;

һава белән кабартылган аттракцион – корылмасы артык һава басымы белән тотыла торган бер яки үзара тоташтырылган берничә тышчадан ясалган аттракцион;

аттракционнар төре – бер төрле эшчәнлек принцибына яки бер төрле функцияләргә ия булган берничә төр аттракционнар җыелмасы;

аттракционнарның өстәмә җайланмалары – декорацияләр һәм бизәлеш элементлары, киртәләр, иллюминацияләр, чатырлар, элмәчләр, саклагыч экраннар, павильоннар, аттракционнар белән берлектә кулланыла торган павильоннар;

аттракционнарны әйләнешкә кертү – аларны түләүсез яки түләүле нигездәге коммерция эшчәнлеге барышында Союз территориясендә җәелдерү максатында аттракционнарны китертү яки читтән кертү (шул исәптәнтән әзерләүче складыннан җибәрү яки складка куймыйча гына төяп озату);

потенциаль биомеханик хәтәрлекнең югары дәрәҗәсе (RB-1) – биомеханик йогынтылар нәтиҗәсендә пассажирга (пассажирларга) аның (аларның) гомеренә куркыныч тудыра торган зыян китерү ихтималлыгы;

балалар – буе 90 см башлап 160 см кадәр булган кунаклар, шул исәптән пассажирлар (2-14 яшьлекләр);

бер урыннан икенче урынга күчкәндә хәтәрлек зоналары – бер урыннан икенче урынга күчә торган гәүдәләр тирәли аларга корылмалар яки чит-ят предметлар килеп эләккәндә пассажирларга төрле дәрәҗәдә зыян салынырга мөмкин булган зоналар;

куркынычсызлык контуры – пассажир бер урыннан икенче урынга күчә торган киңлекнең бер өлешен корылмаларның күчмә һәм хәрәкәтсез элементлары белән орыну нәтиҗәсендә җәрәхәт алу куркынычын минимальләштерү яки бетерү мөмкинлеген бирә торган итеп чикләү;

рөхсәт ителмәгән билгеләнештә файдалану – аттракционнан билгеләнеше буенча файдаланмау яки эксплуатация документларындагы таләпләрне бозып файдалану;

потенциаль биомеханик хәтәрлекнең югары дәрәҗәсе (RB-3) – биомеханик йогынтылар нәтиҗәсендә пассажир (пассажирлар) тарафыннан эшкә сәләтлелек дәрәҗәсен вакытлыча югалтып, зыян салыну ихтималлыгы;

потенциаль биомеханик хәтәрлекнең бик түбән дәрәҗәсе (RB-4) – биомеханик йогынтылар нәтиҗәсендә пассажир (пассажирлар) тарафыннан эшкә сәләтлелек дәрәҗәсенең кайсы да булса формасыннан тыш кына зыян салыну ихтималлыгы;

балалар уен мәйданчыгы өчен җиһазлар – бүлмәдә яки ачык мәйданчыкларда балалар индивидуаль тәртиптә яки төркем белән үз ихтыяры һәм кагыйдәләре буенча аның белән яки анда уйный ала торган җиһаз;

файдалануны чикләү – сәламәтлегендә тайпылышлары булган яки буеның озынлыгы, авырлыгы буенча чикләмәләренә бәйле рәвештә, шулай ук үзен-үзе начар хис иткәндә дә, пассажирлар өчен аттракционнан файдалануны чикләү;

пассажир модуле – аттракционның анда пассажирларны бер урыннан икенче урынга күчерү өчен билгеләнгән бер өлеше (арба, кабина, утыргыч);

кунак – аттракционнар яки аттракционнардагы өстәмә җиһазлар зонасында булган кеше;

ел саен үткәрелә торган тикшерү – ел саен уздырыла торган техник хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашырганнан соң аттракционны эшләтүче зат тарафыннан аның чиктән тыш куркыныч компонентларын һәм чиктән тыш куркыныч параметрларын тулысынча тикшерү;

көндәлек тикшерү – аттракционны эшләтүче зат тарафыннан, аны эшләтеп карауларны да кертеп, аттракциондагы эксплуатация документларында күрсәтелгән чиктән тыш куркыныч компонентларының, чиктән тыш куркыныч параметрларының һәм башка өлешләренең эшкә сәләтле булу-булмавын һәм техник торышын тикшерү;

контроль тикшерү – дәүләт контроль (күзәтчелек) органы – әгъза тарафыннан әлеге техник регламент нигезендә, эшләтеп карауны да кертеп, аттракционга карата ярашлылыкны бәяләү турындагы документларны һәм эксплуатация документларын регламентлы тикшерү;

тулы тикшерү – аттракционны эшләтүче зат тарафыннан эксплуатация документарындагы таләпләргә ярашлы рәвештә аттракциондагы барлык чиктән тыш куркыныч компонетларны һәм чиктән тыш куркыныч параметрларны, шулай ук аттракционның башка өлешләренең техник торышын бәяләү (компонентларны (кирәк булган очракта) сүтүне һәм карауны, сынаулар уздырып һәм эшләтеп карауны да кертеп);

потенциаль биомеханик хәтәрлекнең уртача дәрәҗәсе (RB-2) – биомеханик йогынтылар нәтиҗәсендә пассажир (пассажирлар) сәламәтлегенә авыр зыян салыну ихтималлыгы;

аттракционнарның төре – эшләве һәм биомеханик йогынтылар барлыкка китерү буенча охшаш аттракционнар;

тоткарлаучы җайланмалар – биомеханик йогынтылар яки аттракционнардан файдаланганда яки пассажирларның үз-үзләрен тоту рәвешләренә бәйле рәвештә барлыкка килә торган көйләр нәтиҗәсендә пассажирларның куркынычсызлык контуры чикләреннән чыгып китмәвен булдырмас өчен билгеләнгән аттракцион элементлары (мисал өчен, утыргычлар, аяк кысалары, тоткычлар һәм тотып тора торган җайланмалар);

беркетеп куя торган җайланма – аттракционда тизлек артуны пассажир (пассажирлар) курыкмыйча кабул итә алсын өчен пассажир гәүдәсенең билгеле бер торышта тотып тору, бер урыннан икенче урынга күченүен чикләү һәм (яки) әлеге торышын саклау өчен билгеләнгән җайланма;

аттракцион – биомеханик йогынтыны да кертеп, хәрәкәт вакытында пассажирларның күңел ачуы өчен билгеләнгән җайланма;

үзйөрешле аттракцион – транспорт чарасында монтажлана һәм транспортлана торган аттракцион;

биомеханик йогынты – пассажирларга аларны бер урыннан икенче урынга күчерүгә бәйле рәвештә көчләрнең йогынты ясавы;

аттракционны файдалануга тапшыру – Евразия икътисадый берлегенең «Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында» техник регламенты таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү буенча кирәкле процедураларны узганнан соң аттракционның пассажирлар белән эшли башлавы;

чиктән тыш куркыныч компонент – аттракционның, эшләми башлаган очракта, кеше үлеменә китерергә яки кешенең сәламәтлегенә авыр зыян салырга мөмкин булган корылма өлеше, узелы яки детале;

чиктән тыш куркыныч параметр – аттракционның яки аның чиктән тыш куркыныч компонентының, ул бозылган очракта, кеше үлеменә китерергә яки кешенең сәламәтлегенә авыр зыян салырга мөмкин булган әһәмиятле сыйфатламасы;

модификация – проектлана торганы белән чагыштырмача чиктән тыш куркыныч компонент корылмасын үзгәртү яки чиктән тыш куркыныч параметрын үзгәртү;

билгеләнгән ресурс – техник торышына бәйсез рәвештә, шул дәрәҗәгә җиткән вакытта аттракционның эше туктатылырга тиешле суммар эшләү дәрәҗәсе;

билгеләнгән хезмәт срогы – техник торышына бәйсез рәвештә, шул дәрәҗәгә җиткән вакытта аттракционның эше туктатылырга тиешле аттракционны эшләтүнең календарь вакыт озынлыгы;

стационар булмаган аттракцион – корылмасы фундамент булдыруны яки корылманы 0,5 метрдан артык булмаган тирәнлеккә төшерүне яки суүткәргеч, канализация, газ, җылылык белән тәэмин итү буенча инженер-техник челтәрләргә тоташтыруны оештыруны күздә тотмый торган, күп тапкыр җыю һәм сүтү, шулай ук транспорт белән күчерү өчен билгеләнгән аттракцион, шул исәптән аттракционның составы өлеше булган транспорт чарасында монтажлана һәм транспортлана торган аттракцион;

аттракцион проектының куркынычсызлыгын нигезләү – Евразия икътисадый берлегенең (Таможня берлегенең) техник регламентларындагы таләпләргә туры килү-килмәвен раслау өчен аттракционның куркынычсызлыгы турында гамәле аларга кагылмый торган документлар тупланмасы;

аттракцион операторы – аттракционны эшләтүче зат тарафыннан билгеләнгән, аттракцион белән аттракцион килгән кунаклар өчен файдалану мөмкинлегенә ия барлык вакыт дәвамында эксплуатация документларына ярашлы рәвештә дөрес итеп идарә итү өчен җаваплы зат;

аттракционның техник торышын бәяләү (техник таныклау) – аттракционның техник торышын тикшерү, визуаль, үлчәү, җимерелми торган һәм башка контрольлек алымнарын кулланып, аттракционны алга таба билгеле бер чорга куркынычсыз эшләтү мөмкинлеген билгеләү максатларында эксплуатация документлары таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерү буенча эшләр комплексы;

аттракцион паспорты – аттракционны җитештерүченең гарантияләрен таныклый торган белешмәләрне, аттракционның төп параметрлары һәм сыйфатламасы күрсәткечләрен, шулай ук аттракционның ярашлылыгын раслау һәм утильләштерү турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ;

пассажир – аттракционда хәрәкәт итүче кеше;

аттракционнан файдалану кагыйдәләре – пассажирлар һәм килүчеләр өчен проектлаучы (эшләп чыгаручы) зат яки аттракционны эшләтүче зат тарафыннан эшләнгән таләпләр;

эшләтеп карау – эксплуатация документларында тиешле таләп булган очракта, тулысынча пассажирлар белән йөкләнешен имитацияләп, аттракционны пассажирларсыз гына сынап-эшләтеп карау;

проектлаучы (эшләп чыгаручы) зат – аттракцион проектын эшләгән белгеч яки оешма;

төбәк мәгълүмат системасы – аттракционнарны дәүләт теркәвенә алганда дәүләт техник күзәтчелек органы тарафыннан кулланыла торган мәгълүмат системасы;

махсус оешма – илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләү турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә аккредитацияләнгән, аккредитацияләү өлкәсе әлеге Кагыйдәләрне куллану өлкәсенә туры килә торган оешма;

стационар аттракцион – күп тапкырлар җыю һәм сүтү, шулай ук транспортлау өчен билгеләнмәгән, корылмасы фундаменты булуны яки кимендә 0,5 метрга җир астына тирәнәйтүне яисә сууткәргеч, канализация, газ, җылылык белән тәэмин итү буенча инженер-техник челтәрләргә тоташтыруны оештыру кирәклеген күздә тота торган аттракцион;

потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе – нәтиҗәләренең ихтимал авырлыгын исәпкә алып, биомеханик йогынтылар нәтиҗәсендә пассажирга (пассажирларга) төрле дәрәҗәдәге зыян салыну ихтималлыгы. Потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе Евразия икътисадый берлегенең «Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында»гы техник регламентына 2 нче кушымта нигезендә билгеләнә;

аттракцион формуляры – аттракционны җитештерүче затның гарантияләрен таныклый торган белешмәләрне, аттракционның төп параметрларының һәм сыйфатламалары күрсәткечләрен, аттракционның техник торышын чагылдыра торган белешмәләрне, аттракционның ярашлылыгын раслау һәм утильләштерелүе турындагы белешмәләрне, шулай ук аны эшләтү чорында гамәлгә кертелә торган белешмәләрне (эшләү озынлыгы һәм шартлары, техник хезмәт күрсәтү, төзәтү һәм башка белешмәләр) үз эченә алган документ;

аттракционны эшләтүче зат – законлы нигезләрдә аттракционны эшләтүче һәм пассажирларга күңел ачу хезмәтләрен күрсәтү өчен аттракционнан файдаланучы юридик зат яки шәхси эшкуар сыйфатында теркәлгән физик зат;

эксплуатация документы – аттракционны эшләтү кагыйдәләрен билгели һәм (яки) аттракционны җитештергән зат гарантия биргән аттракционның төп параметрлары һәм сыйфатламалыр күрсәткечләрен, шулай ук билгеләнгән хезмәт итү чорында аны эшләтү турындагы гарантияләрне һәм белешмәләрне таныклый торган мәгълүматларны чагылдырган конструкторлык документы (аерым яки башка документлар белән бергә).

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган

күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы яки шәһәр округы шәһәр (авыл) җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәтеннән файдалану турында мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гариза формасы кагыйдәләргә (әлеге Регламентка 1 нче кушымтада) 4 нче кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Теркәү турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесе тапшырып, аттракционнарны теркәү | Кагыйдәләр |
| 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы | Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе һәм Идарә бүлекләре | 1064 номерлы ТР МК карары |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | 1. Аттракционны теркәү (теркәүдән баш тарту), аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык бирү һәм дәүләт теркәү билгесе бирү.<br>2. Аттракционны дәүләт теркәвен яңарту (яңартудан баш тарту).<br>3. Аттракционның дәүләт теркәвен туктату.<br>4. Югалганнары яки куллану өчен яраксызланганнары өчен алмашка теркәү документлары дубликаты бирү (бирүдән баш тарту).<br>5. Элек теркәлгән аттракционның торган урыны буенча вакытлыча дәүләт теркәвенә алу (вакытлыча теркәүгә алудан баш тарту). | Кагыйдәләрнең 17, 27, 28 пунктлары<br>Кагыйдәләрнең 31-34 пунктлары<br>Кагыйдәләрнең 35, 36 пунктлары<br>Кагыйдәләрнең 45-47 пунктлары<br>Кагыйдәләрнең 37-41 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы – гариза һәм документлар теркәлгәннән соң 18 эш көне.<br>Гаризаны карау – Дәүләт техник күзәтчелек органы | Кагыйдәләрнең 17 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | тарафыннан Кагыйдәләрдә каралган документларның тулы комплекты алынган көннән башлап 5 эш көне эчендә, аттракционны вакытлыча теркәгән вакытта – 3 эш көне;<br>Аттракционны карау – аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен нигезләрнең булмавы турында карар кабул ителгән көннән башлап 5 эш көне;<br>Документлар бирү яки кабул ителгән карар турында мәгълүмат җибәрү – әлеге карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне, аттракционны вакытлыча теркәгәндә – 2 эш көне.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә 15 минут эчендә, чират тәртибендә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә | Аттракционны дәүләт теркәвенә алу өчен мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле тарафыннан аттракцион урнашкан урын буенча Дәүләт техник күзәтчелек органына түбәндәге документлар тапшырыла:<br>1) 1 нче кушымтада каралган форма буенча гариза<br>2) мөрәҗәгать итүченең яисә аның вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (гариза биргәндә күрсәтелә);<br>3) мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр документлар вәкил тарафыннан тапшырылса);<br>4) мөрәҗәгать итүченең аттракционнан файдалану хокукын раслый торган документ (аттракционга ия булу һәм аннан файдалану хокукын яки башка законлы | Кагыйдәләрнең 18 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | нигезен раслаучы документ);<br>5) паспорт яки аттракцион формуляры;<br>6) аттракционны эшләтү буенча кулланма;<br>7) аттракционга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау буенча кулланма;<br>8) аттракционны эшләтү, шулай ук техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау таләпләрен үтәүне тәэмин итә торган журналларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәләре (элек файдалануда булган аттракционнар өчен – гариза бирелгән көнгә кадәр кимендә 12 ай өчен, әгәр аттракцион 12 айдан кимрәк файдаланылган булса – аттракционны эшләтү чоры өчен).<br>9) ярашлылык сертификаты яки ярашлылык турында декларация күчермәсе (2016 елның 1 сентябреннән соң әйләнешкә чыгарылган аттракционнар өчен – мәҗбүри, калганнар өчен – булган очракта);<br>10) аттракционны монтажлап (җыеп, урнаштырып) бетергәннән соң кабул итү турында кабул итү-тапшыру сынауларының үткәрелүе, көйләү һәм җайлау турында, шулай ук эчке контрольне оештыру һәм аттракционны куркынычсыз эшләтү өчен җаваплы хезмәткәрләрне билгеләү турындагы мәгълүматларны үз эченә алган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар күчермәләре;<br>11) аттракционның аттракционнарның техник торышына һәм аларны эшләтүгә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми | |

| | | |
|---|---|---|
| | принциплары турында» федераль законның 26³ статьясының 2 пунктындагы 57 пунктчасы нигезендә раслана торган таләпләр исемлегенә туры килүен раслый торган, аттракционны монтажлап (җыеп, урнаштырып) бетергәннән соң махсус оешма тарафыннан бирелгән, аны биргән көннән башлап 12 айдан артык вакыт узмаган («Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында» Евразия икътисадый берлеге техник регламенты үз көченә кергәнчегә кадәр әзерләнгән һәм файдалануга тапшырылган аттракционнар өчен) аттракционның техник торышын бәяләү (техник таныклау) акты;<br>12) билгеләнгән маршрут буенча йөрүче аттракцион хәрәкәте маршруты турында белешмәләр (үзйөрешле аттракционнар өчен);<br>13) тикшерү нәтиҗәләре буенча махсус оешма тарафыннан бирелгән, аттракционны эшләтү шартлары һәм аны эшләтү вакытын озайту мөмкинлеге турында мәгълүматларны үз эченә алган бәяләмә (хезмәт итү вакыты чыккан яки проектчы, завод-җитештерүче тарафыннан билгеләнгән ресурсы беткән яисә тикшерү нәтиҗәләре буенча махсус оешма тарафыннан элегрәк бирелгән бәяләмәдә билгеләнгән срок узган булса);<br>14) аттракционны эшләткән вакытта физик затларның гомеренә һәм (яки) сәламәтлегенә, физик яки юридик затларның мөлкәтенә, дәүләт яки муниципаль милеккә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китергән өчен аттракцион хуҗасының гражданлык җаваплылыгы буенча иминият полисы күчермәсе (булган очракта);<br>15) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик затлар өчен); | |

| | | |
|---|---|---|
| | 16) мөрәҗәгать итүче тарафыннан аттракционның потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсен билгеләгәндә файдаланылган документлар (Кагыйдәләрнең 15 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгәннәрдән тыш башка документлардан файдаланган очракта).<br>2016 елның 1 сентябренә кадәр файдалануга тапшырылган аттракционнарга карата әлеге пунктның алтынчы-сигезенче абзацларында күрсәтелгән документлар урынына әлеге пунктларда каралган белешмәләр булган эксплуатация буенча кулланма яки эксплуатация буенча кулланма һәм башка документ (документлар) тапшырырга рөхсәт ителә.<br>Аттракционнарны дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырыла торган, рус телендә төзелмәгән документлар, тапшырылган тәрҗемәне таныклап, рус теленә тәрҗемә ителергә тиеш. | Кагыйдәләрнең 19 пункты |
| | Аттракционның дәүләт теркәвен яңарту өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1) 1 нче кушымтада каралган форма буенча гариза<br>2) мөрәҗәгать итүченең яисә аның вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (гариза биргәндә күрсәтелә);<br>3) мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр документлар вәкил тарафыннан тапшырылса);<br>4) аттракционның дәүләт теркәве туктатылу сәбәпләрен бетерүне раслаучы документлар (аттракционны түбәндәге нигезләр буенча дәүләт теркәве туктатылудан тыш:<br>а) аттракцион авария аркасында эксплуатацияләүдән | Кагыйдәләрнең 31 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | туктатылганда;<br>б) үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда дәүләт техник күзәтчелек органы дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан Кагыйдәләрнең 50 пунктындагы «м» пунктчасында каралган аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен нигезе ачыкланса:<br>аттракцион «Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында» Евразия икътисадый берлеге Техник регламенты (2018 елның 18 апреленнән беренче тапкыр файдалануга тапшырылган аттракционнарга карата) таләпләренә яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә (2018 елның 18 апреленә кадәр беренче тапкыр файдалануга тапшырылган аттракционнарга карата).<br>5) әлеге пунктның 4 пунктындагы «а» яки «б» пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча дәүләт теркәве туктатылган аттракционга карата, аттракционны модификацияләү яисә капиталь ремонтлау тәмамланганнан соң яисә авария нәтиҗәләрен бетергәннән соң махсус оешма тарафыннан бирелгән аттракционның (техник тикшерү) техник торышын бәяләү акты өстәмә рәвештә тапшырыла.<br>Элек теркәлгән аттракционның торган урыны буенча вакытлыча дәүләт теркәвенә алу өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1) 1 нче кушымтада каралган форма буенча гариза<br>2) мөрәҗәгать итүченең яисә аның вәкиленең шәхесен | Кагыйдәләрнең 37 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | таныклаучы документ (гариза биргәндә күрсәтелә);<br>3) мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр документлар вәкил тарафыннан тапшырылса);<br>4) мөрәҗәгать итүченең аттракционнан файдалану хокукын раслый торган документ (аттракционга ия булу һәм аннан файдалану хокукын яки башка законлы нигезен раслаучы документ);<br>5) паспорт яки аттракцион формуляры;<br>6) аттракционны эшләтү, шулай ук техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау таләпләрен үтәүне тәэмин итә торган журналларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәләре (элек файдаланудагы булган аттракционнар өчен – гариза бирелгән көнгә кадәр кимендә 12 ай өчен, әгәр аттракцион 12 айдан кимрәк файдаланылган булса – аттракционны эшләтү чоры өчен).<br>7) аттракционны монтажлап (җыеп, урнаштырып) бетергәннән соң кабул итү турында кабул итү-тапшыру сынауларының үткәрелүе, көйләү һәм җайлау турында, шулай ук эчке контрольне оештыру һәм аттракционны куркынычсыз эшләтү өчен җаваплы хезмәткәрләрне билгеләү турындагы мәгълүматларны үз эченә алган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар күчермәләре;<br>8) аттракционның аттракционнарның техник торышына һәм аларны эшләтүгә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми | |

| | | |
|---|---|---|
| | принциплары турында» федераль законның 26[3] статьясының 2 пунктындагы 57 пунктчасы нигезендә раслана торган таләпләр исемлегенә туры килүен раслый торган, аттракционны монтажлап (җыеп, урнаштырып) бетергәннән соң махсус оешма тарафыннан бирелгән, аны биргән көннән башлап 12 айдан артык вакыт узмаган («Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында» Евразия икътисадый берлеге техник регламенты үз көченә кергәнчегә кадәр әзерләнгән һәм файдалануга тапшырылган аттракционнар өчен) аттракционның техник торышын бәяләү (техник таныклау) акты;<br>9) билгеләнгән маршрут буенча йөрүче аттракцион хәрәкәте маршруты турында белешмәләр (үзйөрешле аттракционнар өчен);<br>10) тикшерү нәтиҗәләре буенча махсус оешма тарафыннан бирелгән, аттракционны эшләтү шартлары һәм аны эшләтү вакытын озайту мөмкинлеге турында мәгълүматларны үз эченә алган бәяләмә (хезмәт итү вакыты чыккан яки проектчы, завод-җитештерүче тарафыннан билгеләнгән ресурсы беткән яисә тикшерү нәтиҗәләре буенча махсус оешма тарафыннан элегрәк бирелгән бәяләмәдә билгеләнгән срок узган булса);<br>11) аттракционны эшләткән вакытта физик затларның гомеренә һәм (яки) сәламәтлегенә, физик яки юридик затларның мөлкәтенә, дәүләт яки муниципаль милеккә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китергән өчен аттракцион хуҗасының гражданлык җаваплылыгы буенча иминият полисы күчермәсе (булган очракта);<br>12) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик затлар өчен); | |

| | | |
|---|---|---|
| | 13) аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык.<br>Аттракционның дәүләт теркәвен туктату өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1) 1 нче кушымтада каралган форма буенча гариза<br>2) мөрәҗәгать итүченең яисә аның вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (гариза биргәндә күрсәтелә);<br>3) мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр документлар вәкил тарафыннан тапшырылса);<br>4) мөрәҗәгать итүченең аттракционнан файдалану хокукын раслый торган документ (аттракционга ия булу һәм аннан файдалану хокукын яки башка законлы нигезен раслаучы документ);<br>5) паспорт яки аттракцион формуляры;<br>6) аттракционны эшләтү буенча кулланма;<br>7) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик затлар өчен);<br>8) аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесе. | Кагыйдәләрнең 35, 36 пунктлары |
| | Аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык дубликатын алу өчен яки дәүләт теркәү билгесен алу өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1) 1 нче кушымтада каралган форма буенча гариза<br>2) мөрәҗәгать итүченең яисә аның вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (гариза биргәндә күрсәтелә);<br>3) мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр документлар вәкил тарафыннан тапшырылса);<br>4) мөрәҗәгать итүченең аттракционнан файдалану | РФ Хөкүмәтенең 1939 номерлы карарының 45 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | хокукынраслый торган документ (аттракционга ия булу һәм аннан файдалану хокукын яки башка законлы нигезен раслаучы документ);<br>5) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик затлар өчен);<br>6) аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, әгәр югалмаган булса.<br><br>Гаризалар бирү тәртибе:<br>1. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Дәүләт теүник күзәтчелек идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Идарәнең рәсми сайтында урнаштырылган.<br>2. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы аша.<br>3. Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 4. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Документлар бер нөсхәдә тапшырыла. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Дәүләт техник күзәтчелек органы түбәндәгеләрне ала:<br>1) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан, Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>2) аттракционны кадастр исәбенә кую турында белешмәләр (аттракцион капиталь төзелеш объекты булган очракта);<br>3) транспорт чарасын дәүләт теркәвенә алу һәм аларга техник карау узу турында белешмәләр (аттракцион транспорт чарасына монтажланган очракта);<br>4) дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат;<br>5) төбәк мәгълүмат системасыннан – аттракцион турында мәгълүмат.<br>«1» - «4» пунктчаларында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкиле тарафыннан үз инициативасы белән дә тапшырылырга мөмкин.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә 2016 елның 1 сентябреннән әйләнешкә чыгарылган аттракционга карата тапшырылган документлар нигезендә | Кагыйдәләрнең 21 пункты<br><br>«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә<br><br>Кагыйдәләрнең 22 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | аттракционны идентификацияләү мөмкин булмаса һәм (яки) ярашлылык сертификатында (ярашлылык турында декларациядә) аттракционның потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе турында белешмәләр булмаса, дәүләт техник күзәтчелек органы сертификацияләүче органнан яки җитештерүчедән (яки аттракционның ярашлылыгын раслау процедураларын уздырганда гариза бирүче заттан) аттракцион проектының куркынычсызлыгына нигезләү һәм сынаулар беркетмәләрен соратып ала.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче мәртәбә баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документларның тапшырылмавы.<br>2. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм башка, шулай ук карандаш белән ясалган, төзәтмәләр булуы. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.<br>Аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>1) Кагыйдәләр нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле булмаган аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итү;<br>2) Кагыйдәләр нигезендә мәҗбүри булырга тиешле документлар яки белешмәләр булмау;<br>3) тапшырылган документларның норматив хокукый актларда яисә норматив-техник документларда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>4) гамәлдә булу вакыты чыккан документлар тапшыру;<br>5) тапшырылган документларның гамәлдән чыгуы турында белешмәләр булу;<br>6) тапшырылган (алынган) документларда | Кагыйдәләрнең 50 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | (белешмәләрдә) каршылыклы яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу;<br>7) вәкаләтле дәүләт органының аттракционга карата юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылуны туктатып тору (тыю) турында карары булу;<br>8) караган вакытта фактик билгеләнгән белешмәләрнең тапшырылган (алынган) документларга (белешмәләргә) туры килмәве;<br>9) төбәк мәгълүмат системасында аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гамәле бетмәгән белешмәләр булу (аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә);<br>10) төбәк мәгълүмат системасында аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гамәле бетмәве турында мәгълүмат булмавы (аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итүдән тыш);<br>11) төбәк мәгълүмат системасында аттракционны дәүләт теркәвенә алуны туктату турында мәгълүматлар булуы: аттракционны дәүләт теркәвенә алуны туктату турында суд карары үз көченә кергән, аттракционны дәүләт теркәвенә алу туктатылган көннән алып 12 ай вакыт узган, һәм аттракционны дәүләт теркәвенә алу яңадан торгызылмаган, мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан аттракционны дәүләт теркәвенә алуны туктату турында гариза бирелгән.<br>12) аттракционның «Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында» Евразия икътисадый берлеге Техник регламенты (2018 елның 18 апреленнән беренче тапкыр файдалануга тапшырылган аттракционнарга карата) таләпләренә яисә Россия | |

| | | |
|---|---|---|
| | Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве (2018 елның 18 апреленә кадәр беренче тапкыр файдалануга тапшырылган аттракционнарга карата). | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | 1) аттракционны дәүләт теркәвенә алу (дәүләт теркәвен яңарту), шул исәптән аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аттракционга дәүләт теркәве билгесен биреп, түбәндәгечә түләү алына:<br>потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе югары булганда (RB-1) - 13 000 сум;<br>потснциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе уртача булганда (RB-2) - 7 000 сум;<br>потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе түбән булганда (RB-3) - 3 500 сум;<br>2) элек теркәлгән аттракционның торган урыны буенча вакытлыча дәүләт теркәвенә алу өчен:<br>потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе югары булганда (RB-1) - 2 400 сум;<br>потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе уртача булганда (RB-2) - 1 800 сум;<br>потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе түбән булганда (RB-3) - 1 300 сум;<br>3) аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык дубликатын биргән өчен - 600 сум;<br>4) аттракционга карата кылынган теркәү гамәлләре турында белешмә биргән өчен - 600 сум;<br>5) аттракционга югалган яки яраксызга килгән урынына алмаш итеп дәүләт теркәү билгесен биргән өчен - 1 500 сум. | РФ Салым кодексының 333.33 статьясының 139-143 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү | Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гаризаны һәм документларны тапшырган көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Идарә, Идарә бүлекләре биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Идарәнең рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә | |

| | | |
|---|---|---|
| алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки аннан файдалана алмау | ярдәм күрсәтелүе.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>Идарә, Идарә бүлекләре белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>Мөрәҗәгать итүченең Идарә, Идарә бүлекләре белгечләре белән бәйләнешкә кереп, хезмәттәшлек итү күләме:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда, турыдан-туры – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә бер тапкырдан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый<br>Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарына мөрәҗәгать иткәндә, күпфункцияле үзәк белгече, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарындагы белгечләр консультацияли һәм документларны кабул итә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан сайтта (http://gtn.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru), күпфункцияле үзәктә (гариза күпфункцияле үзәк аша тапшырылган очракта) алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештәге гаризаны, алга таба документларның төп нөсхәләрен тапшыру юлы белән, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеге бар. | 63-ФЗ номерлы федераль закон, 210-ФЗ номерлы федераль закон |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

тапшырылган документларны һәм белешмәләрне тикшерү, аттракционны документация буенча идентификацияләү;

аттракционны карау;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм/яки Идарә бүлекләренә мөрәҗәгать итә.

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең һәм/яки Идарә бүлекләренең белгече, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, тапшырыла торган документларның формасы һәм эчтәлеге буенча һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләрдә мөрәҗәгать итүчене консультацияли, зарурлык булганда гаризаны рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның формасы һәм эчтәлеге буенча һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләрдә мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, зарурлык булганда гаризаны рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән кәгазьдә яки электрон формада Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә, Идарә бүлегенә аттракционны дәүләт теркәвенә алу, аттракционны дәүләт теркәвенә алуны яңарту, аттракционның дәүләт теркәвен туктату, торган урыны буенча вакытлыча аттракционны вакытлыча дәүләт теркәвенә алу, аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык дубликаты бирү, югалган яки яраксызга килгәне урынына алмашка аттракционга дәүләт теркәвенә алу тамшасын бирү турында, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны теркәп, гариза (алга таба – гариза) тапшырыла.

3.3.2. Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү;

документларны норматив актларда билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе предметына тикшерү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында билгеләнгән нигезләр булган очракта, мөрәҗәгать итүчегә баш тарту сәбәпләрен язмача нигезләп, документлар кайтарып бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар яки документларны кабул итүдән язмача баш тарту.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә, түбәндәгеләрне бирү турында:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә);

аттракционны кадастр исәбенә кую турында белешмәләр (аттракцион капиталь төзелеш объекты булган очракта);

транспорт чарасын дәүләт теркәвенә алу һәм аларга техник карау узу турында белешмәләр (аттракцион транспорт чарасына монтажланган очракта);

дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат бирү (Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсенә);

төбәк мәгълүмат системасыннан – аттракцион турында мәгълүмат.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документларны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматларны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматларның булмавы турында белдерү җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү.

3.5. Тапшырылган документларны һәм белешмәләрне тикшерү, аттракционны документация буенча идентификацияләү.

3.5.1. Аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, баш дәүләт инженер-инспекторы аттракцион милекчесе белән аттракционны карау датасын, урынын һәм вакытын килештерелә.

3.5.2. Тапшырылган документларны һәм белешмәләрне тикшерү вакытында, аттракционны идентификацияләү барышында аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен Кагыйдәләрнең 50 пунктында күрсәтелгән нигезләр булуы ачыкланган очракта, аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту турында

мөрәҗәгать итүчегә язмача белдерү әзерләнә һәм җибәрелә.

Аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) Кагыйдәләр нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле булмаган аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итү;

2) Кагыйдәләр нигезендә мәҗбүри булырга тиешле документлар яки белешмәләр булмау;

3) тапшырылган документларның норматив хокукый актларда яисә норматив-техник документларда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

4) гамәлдә булу вакыты чыккан документлар тапшыру;

5) тапшырылган документларның гамәлдән чыгуы турында белешмәләр булу;

6) тапшырылган (алынган) документларда (белешмәләрдә) каршылыклы яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу;

7) вәкаләтле дәүләт органының аттракционга карата юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылуны туктатып тору (тыю) турында карары булу;

8) караган вакытта фактик билгеләнгән белешмәләрнең тапшырылган (алынган) документларга (белешмәләргә) туры килмәве;

9) төбәк мәгълүмат системасында аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гамәле бетмәгән белешмәләр булу (аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә);

10) төбәк мәгълүмат системасында аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гамәле бетмәве турында мәгълүмат булмавы (аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итүдән тыш);

11) төбәк мәгълүмат системасында аттракционны дәүләт теркәвенә алуны туктату турында мәгълүматлар булуы: аттракционны дәүләт теркәвенә алуны туктату турында суд карары үз көченә кергән, аттракционны дәүләт теркәвенә алу туктатылган көннән алып 12 ай вакыт узган, һәм аттракционны дәүләт теркәвенә алу яңадан торгызылмаган, мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан аттракционны дәүләт теркәвенә алуны туктату турында гариза бирелгән.

12) аттракционның «Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында» Евразия икътисадый берлеге Техник регламенты (2018 елның 18 апреленнән беренче тапкыр файдалануга тапшырылган аттракционнарга карата) таләпләренә яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве (2018 елның 18 апреленә кадәр беренче тапкыр файдалануга тапшырылган аттракционнарга карата).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура белешмәләр алынган вакыттан башлап 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту яки аттракционны карау турында карар кабул итү.

3.6. Аттракционны карау.

3.6.1. Кагыйдәләрнең 29 пунктындагы «б» яки «в» пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча (аттракционны теркәү һәм аннан файдалануның законлы нигезен раслый торган документның гамәлдә булу срогы чыккан, һәм

аттракционны теркәү урыны буенча Дәүләт техник күзәтчелек органына тиешле срокны озайту турында документ яки шул ук эксплуатантны күрсәтеп, яңа документ тапшырылмаган; аттракционны модификацияләү яки капиталь ремонтлау башкарылган) үзенә карата дәүләт теркәве тутатылып торган аттракционның дәүләт теркәвен торгызу турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, әгәр дәүләт теркәвенә алуны туктату өчен башка нигезләр булмаса, аттракцион каралмый һәм аны пассажирларсыз эшләтеп карау гамәлгә ашырылмый.

Аттракционны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык дубликатын яки аттракционның дәүләт теркәү билгесе дубликатын бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, аттракцион каралмый.

3.6.2. Аттракционны караганда аттракцион визуаль алым белән тәңгәлләштерелә, аттракционның маркировкасы һәм аның тапшырылган документларына туры килүе һәм түбәндәгеләрнең булу-булмавы тикшерелә:

а) аттракционга керү юлында килүчеләр өчен урнаштырылган аттракционнан файдалану кагыйдәләре, шулай ук инвалид пассажирларга хезмәт күрсәтү кагыйдәләре, әгәр аттракционның биомеханик йогынтысы алар өчен ярарлык булмаса, сәламәтлек торышы буенча, яшькә, буй озынлыгына һәм тән авырлыгына бәйле рәвештә аттракционнан файдаланудагы чикләмәләр турында мәгълүмат (әгәр дә бу аттракционны эшләтү документларында каралган булса), тикшерү үткәргән оешма күрсәтелгән соңгы еллык тикшерү датасы турында мәгълүмат һәм алдагы еллык тикшерүнең датасы турында күрсәтелгән мәгълүмат тактасы;

б) пассажирларның буй озынлыгын һәм тән авырлыгын үлчәү чаралары (әгәр эксплуатация документларында аттракционнан файдалану өчен буй озынлыгы һәм тән авырлыгы буенча чикләүләр каралган булса);

в) аттракцион пульты янында урнаштырылган, аттракционның төп техник сыйфатламалары турындагы белешмәләрне үз эченә алган табличкалар;

г) пассажирлар белән аттракционны йөкләү схемалары (әгәр бу эксплуатация документларында каралган булса);

д) эш урынында урнаштырылган, хезмәт күрсәтүче персоналга карата, чиктән тыш куркыныч компонентларга һәм чиктән тыш куркыныч параметрларга карата көндәлек тикшерүләр тәртибенә карата таләпләрне, аттракционга хезмәт күрсәтү буенча төп кагыйдәләргә кагылышлы табличкалар;

е) медицина аптечкалары;

ж) урнаштырылган кирәкле эвакуация билгеләре;

з) зур биеклектән яки җиргә карата шактый авыш креслолардан пассажирларны эвакуацияләү буенча чаралар турында план һәм мәгълүмат (эксплуатация документлары нигезендә);

1) пассажирларны пассажир модульләреннән эвакуацияләү чаралары (әгәр бу эксплуатация документларында каралган булса);

к) аттракцион эше вакытында һәм ул эшләмәгән вакытта килгән кунакларның куркыныч зоналарга (пассажирлар модульләре, механизмнар хәрәкәте зоналары, электр җиһазлары белән шкафлар, платформа һәм хезмәт күрсәтүче персонал өчен баскычлар) ирекле үтеп керүен булдырмый торган

эксплуатация документларында каралган коймалар һәм башка чаралар;

л) аттракцион мәйданында җил көчен һәм әйләнә-тирә һава температурасын үлчәү өчен билгеләнгән приборлар (эксплуатация документларында җил яки температурага карап, аттракционны куллану буенча чикләүләр каралган булса);

м) аттракционны эшләтү, шулай ук техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау таләпләрен үтәүне тәэмин итә торган журналларның оригиналлары (элек файдалануда булган аттракционнар өчен – гариза бирелгән көнгә кадәр кимендә 12 ай өчен, әгәр аттракцион 12 айдан кимрәк файдаланылган булса – аттракционны эшләтү чоры өчен).

Аттракционны караганда, видеофиксация (эксплуатант яки аның вәкиле катнашында) үткәрү юлы белән, аны сынап эшләтеп карыйлар.

Аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен нигезләрне карау нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) язма рәвештә баш тарту нигезләре турында хәбәр ителә.

Аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен нигезләр булмаганда, аттракционны дәүләт теркәвенә алу, аттракционны дәүләт теркәвенә алуны яңарту, аттракционның дәүләт теркәвен туктату, торган урыны буенча вакытлыча аттракционны вакытлыча дәүләт теркәвенә алу, аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык дубликаты бирү, югалган яки яраксызга килгәне урынына алмашка аттракционга дәүләт теркәвенә алу тамшасын бирү турында карар кабул ителә

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар аттракционны карау турында карар кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: аттракционны дәүләт теркәвенә алу, аттракционны дәүләт теркәвенә алуны яңарту, аттракционның дәүләт теркәвен туктату, торган урыны буенча вакытлыча аттракционны вакытлыча дәүләт теркәвенә алу, аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык дубликаты бирү, югалган яки яраксызга килгәне урынына алмашка аттракционга дәүләт теркәвенә алу тамшасын бирү турында карар.

3.7. мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Аттракционны дәүләт теркәвенә алу, аттракционны дәүләт теркәвенә алуны яңарту, аттракционның дәүләт теркәвен туктату, торган урыны буенча вакытлыча аттракционны вакытлыча дәүләт теркәвенә алу, аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык дубликаты бирү, югалган яки яраксызга килгәне урынына алмашка аттракционга дәүләт теркәвенә алу тамшасын бирү турында карар кабул ителгәннән соң түбәндәге гамәлләр башкарыла:

аттракцион турында мәгълүматларны автоматлаштырылган исәпкә алу системасына кертү;

дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкны бастырып чыгару;

машина хуҗасына, кул куйдыртып, дәүләт теркәү билгесе, аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык бирү;

аттракцион паспортында (формулярында) аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында билгеләү.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан

соң 3 эш көне дәвамында (аттракционны вакытлыча теркәгәндә – 2 эш көне) гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүнең бирелгән нәтиҗәсе, дәүләт теркәү билгесе, дәүләт теркәве турында таныклык.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән кәгазьдә яисә электрон формада Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән техник хаталарны (язу, басма хаталарны, грамматик яки арифметик ялгышларны) бетерү турында гариза тапшырыла.

Үзгәртеп рәсмиләштерү эше мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан бирелгән, техник хатасы булган документны теркәп теркәүгә алынган гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

Баш дәүләт инженер-инспекторы:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында (1 нче кушымта) терки;

аттракцион турында мәгълүматларны автоматлаштырылган исәпкә алу системасына кертү;

техник хатасы булган документны үзгәртеп рәсмиләштерә.

Баш дәүләт инженер-инспекторы мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән документ турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору Идарә башлыгы, Идарә бүлегендәге вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Идарә бүлекләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1' өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе (Идарә бүлекләре) хезмәткәрләре, Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе, Идарә бүлекләренең, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Идарә бүлеге хезмәткәрләре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Идарәнең бүлек башлыгына бирелә.

Идарә бүлеге башлыгы карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Идарәгә тапшырыла.

Идарә башлыгы карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Күпфункцияле үзәк карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Күпфункцияле үзәк оештыручы тарафыннан бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять

белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең http://gtn.tatarstan.ru рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең)

бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

## 6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә гариза җибәрү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең http://mfc16.tatarstan.ru/ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урынына тапшыра.

6.3.2. Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә гариза җибәрү.

6.4.2. Күпфункцияле үзәк белгече гаризаны Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә, Идарә бүлегенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе һәм күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә юлланган гариза.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.5.1. Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән бәяләмәдә хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы заты аша күпфункцияле үзәккә язмача тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

6.6.2. Күпфункцияле үзәк белгече Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы

гаризаны Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә җибәрә.

Теркәү турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесен биреп, аттракционнарны теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе бүлеге башлыгына

______________________________________________
бүлекнең территориаль атамасы, район, шәһәр күрсәтелә

баш дәүләт инженер-инспекторы

______________________________________________
Инженер-инспекторның Ф.И.А.

Кемнән______________________________________________________________
____________________________________________________________________
(юридик затның, шәхси эшкуарның тулы исеме)
Индекс ___________________________________Адрес_____________________________
____________________________________________________________________
Телефон _______________________ОГРН (ОГРНИП) _____________________ИНН ________
Электрон почта__________________________________________________________

## Гариза

Үтенәм__________________________________________________________
(аттракционны теркәү, аттракционның дәүләт теркәвен торгызу, аттракционның дәүләт теркәвен туктату, элек теркәлгән аттракционны торган урыны буенча вакытлыча дәүләт теркәвенә алу, аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык дубликаты бирү, аттракционга югалган яки яраксызга килгәне урынына алмашка дәүләт теркәү билгесе бирү, баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан җибәрелгән техник хатаны (язу, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) бетерү турында)

____________________________________________________________________
(аттракционның паспорты яки формуляры нигезендә атамасы)
Стационар/стационар булмаган (кирәкмәгәнен сызарга);
Потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе RB- ________________________________
Аттракцион төре________________________________________________________
Аттракцион тибы________________________________________________________
Завод номеры___________________________________________Чыгарылган елы__________
Җитештерүче-оешма______________________________________________________
Эксплуатант____________________________________________________________
(тулы исеме, ОГРН (ОГРНИП), ИНН)
Аттракцион түбәндәге адрес буенча урнаштырылган:
____________________________________________________________________
Географик координаталар:
____________________________________________________________________
Теркәлә торган документлар исемлеге:
1.__________________________________________________________________

2.__________________________________________________________________

3.__________________________________________________________________

4.__________________________________________________________________

5.______________________________________________________________________

6.______________________________________________________________________

7.______________________________________________________________________

8.______________________________________________________________________

9.______________________________________________________________________

10._____________________________________________________________________

11._____________________________________________________________________

12._____________________________________________________________________

______________________________ ______________________________

(гариза бирүче затның имзасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

______________________________________________________________________

(шәхесне раслаучы документ исеме, серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Документ-
лар кабул
итү
турында
билге

__________________________________»______» ___________ 20 ______ ел.

(дәүләт инженер-инспекторының имзасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча:

Түбәндәгеләрне дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар бирелде:

______________________________________________________________________

Дәүләт теркәү билгесе:

______________________________________________________________________

Карар «_______» ____________ 20_____ел. № __________ _________ биттә.

Түбәндәге пунктларда күрсәтелгән документлар кире кайтарылды

______________________________________

(санап чыгарга)

Теркәлгән документлар исемлеге.

______________________________________ ______________________________

(дәүләт инженер-инспекторының имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________ ______________________________

(дәүләт инженер-инспекторының имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

«____»________________20____ ел.

Теркәү турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесен биреп, аттракционнарны теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары.

**Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең структур бүлекчәсе аталышы**

| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең структур бүлекчәсе аталышы | Код | Телефон | Индекс | Адрес |
|---|---|---|---|---|
| Әгерҗе шәһәре һәм Әгерҗе муниципаль районы буенча ТР Дәүләт техник күзәтчелек бүлеге | 85551 | 2-20-43 | 422230 | Әгерҗе шәһәре, Гагарин урамы, 70 йорт |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Азнакай шәһәре һәм Азнакай муниципаль районы бүлеге | 85592 | 7-02-76 | 423330 | Азнакай шәһәре, Нефтьчеләр урамы, 23А |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Аксубай муниципаль районы бүлеге | 84344 | 2-89-18 | 423060 | Аксубай ш.т.п., Ленин урамы, 8 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Актаныш муниципаль районы бүлеге | 85552 | 3-13-16 | 423740 | Актаныш авылы, Ленин урамы, 4Б |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Алексеевск муниципаль районы бүлеге | 84341 | 2-32-74 | 422900 | Алексеевск ш.т.п., Совет урамы, 6 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Әлки муниципаль районы бүлеге | 84346 | 2-16-68 | 422870 | Базарлы Матак авылы, Крайнов урамы, 58 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт муниципаль районы бүлеге | 8553 | 37-47-87 | 423450 | Әлмәт шәһәре, Обьездная урамы, 65 йорт, 1002 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Апас муниципаль районы бүлеге | 84376 | 21-4-54 | 422350 | Апас авылы, Гагарин урамы, 11 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Арча муниципаль районы бүлеге | 84366 | 3-22-66 | 422000 | Арча штп., Галактионов урамы, 40 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Әтнә муниципаль районы бүлеге | 84369 | 2-10-43 | 422750 | Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 38 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Баулы шәһәре һәм Баулы муниципаль районы бүлеге | 85569 | 5-77-25 | 423930 | Баулы шәһәре, Ваһапов урамы, 46А йорты |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Балтач муниципаль районы бүлеге | 84368 | 2-52-28 | 422250 | Балтач ш.т.п., В.Булатов урамы, 24/2 йорт |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Бөгелмә шәһәре һәм Бөгелмә муниципаль районы бүлеге | 85594 | 4-14-46 | 423230 | Бөгелмә шәһәре, Я. Гашек урамы, 3 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Буа шәһәре һәм Буа муниципаль районы бүлеге | 84374 | 3-15-97 | 422400 | Буа шәһәре, Космовский урамы, 31 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Югары Ослан муниципаль районы бүлеге | 84379 | 2-17-80 | 422570 | Югары Ослан, Чехов урамы, 18 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Биектау муниципаль районы бүлеге | 84365 | 2-36-79 | 422700 | Биектау тимер юл станциясе, Школьная урамы, 17 йорт |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Чүпрәле муниципаль районы бүлеге | 84375 | 2-23-79 | 422470 | Иске Чүпрәле, Газовая урамы, 10 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районы бүлеге | 85557 | 38-6-78 | 423604 | Алабуга шәһәре, Т. Гыйззәт урамы, 29 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Зәй шәһәре һәм Зәй муниципаль районы бүлеге | 85558 | 7-08-15 (14) | 423520 | Зәй шәһәре, Н. Крупская урамы, 6 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы бүлеге | 84371 | 5-77-88 | 422540 | Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 38 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Кайбыч муниципаль районы бүлеге | 84370 | 2-11-15 | 422330 | Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 15 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Кама Тамагы муниципаль районы бүлеге | 84377 | 2-19-09 | 422820 | Кама Тамагы ш.т.п., К. Маркс урамы, 2 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Кукмара муниципаль районы бүлеге | 84364 | 2-74-86 | 422110 | Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 28 йорт |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Лаеш шәһәре һәм Лаеш | 84378 | 2-81-80 | 422610 | Лаеш шәһәре, Горький урамы, 8 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| муниципаль районы бүлеге | | | | |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Лениногорск шәһәре һәм Лениногорск муниципаль районы бүлеге | 85595 | 5-02-44 | 423250 | Лениногорск шәһәре, Гончаров урамы, 1 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мамадыш шәһәре һәм Мамадыш муниципаль районы бүлеге | 85563 | 3-35-89 | 422192 | Мамадыш шәһәре, Толстой урамы, 23 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Менделеевск шәһәре һәм Менделеевск муниципаль районы бүлеге | 85549 | 2-00-22 | 423650 | Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Минзәлә шәһәре һәм Минзәлә муниципаль районы бүлеге | 85555 | 3-27-92 | 423700 | Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 80 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мөслим муниципаль районы бүлеге | 85556 | 2-59-96 | 423970 | Мөслим авылы, Пушкин урамы, 91А |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы бүлеге | 8555 | 47-32-28 | 423550 | Түбән Кама шәһәре, Корабельная урамы, 40 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Яңа Чишмә муниципаль районы бүлеге | 84348 | 2-21-37 | 423190 | Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 37А |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы бүлеге | 84345 | 2-06-93 | 423040 | Нурлат шәһәре, Совет урамы, 117 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Питрәч муниципаль районы бүлеге | 84367 | 3-06-59 | 422770 | Питрәч авылы, Совет урамы, 20 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Балык Бистәсе муниципаль районы бүлеге | 84361 | 2-34-97 | 422650 | Балык Бистәсе авылы, Ленин урамы, 48 А |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Саба муниципаль районы бүлеге | 84362 | 2-32-66 | 422060 | Байлар Сабасы авылы, Г. Закиров урамы, 52 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Сарман муниципаль районы бүлеге | 85559 | 2-50-57 | 423362 | Сарман авылы, Куйбышев урамы, 36 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Болгар шәһәре һәм Спас муниципаль районы бүлеге | 84347 | 3-01-21 | 422840 | Болгар шәһәре, Хирург Шеронов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | урамы, 21 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Тәтеш шәһәре һәм Тәтеш муниципаль районы бүлеге | 84373 | 2-55-60 | 422370 | Тәтеш шәһәре, Свердлов урамы, 61 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Чаллы шәһәре һәм Тукай муниципаль районы бүлеге | 8552 | 70-18-19 | 423800 | Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил проспекты, 46 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Теләче муниципаль районы бүлеге | 84360 | 2-16-11 | 422080 | Теләче авылы, Ленин урамы, 46 йорт |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Чирмешән муниципаль районы бүлеге | 84396 | 2-55-77 | 423100 | Чирмешән авылы, Техническая урамы, 36 |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Чистай шәһәре һәм Чистай муниципаль районы бүлеге | 84342 | 5-25-60 | 422980 | Чистай шәһәре, К. Маркс урамы, 61Б |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Ютазы муниципаль районы бүлеге | 85593 | 2-73-13 | 423950 | Урыссу ш.т.п., Пушкин урамы, 38 йорт |
| ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Казан шәһәре бүлеге | 843 | 273-54-50 | 420073 | Казан шәһәре, Спорт урамы, 33 |

Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Идарә башлыгы | 221-77-85 | gostehnadzorrt@mail.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы | 264-77-15 | prav@tatar.ru |

## ЭЛЕКТРОН ДОКУМЕНТ ФОРМАСЫНДА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ АЛУ ӨЧЕН ЭЛЕКТРОН АДРЕСЛАР

| **Район/шәһәр** | **ФИА** | **Эл.почта** |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| Әгерҗе | Гыймазов Камил Вәгыйз улы | Kamil.Gimazov@tatar.ru |
| Азнакай | Хәмитов Илназ Фазыл улы | Ilnaz.Hamitov@tatar.ru |
| Аксубай | Бикмөхәммәтов Илдар Минсәгыйт улы | Bikmuhametov.Ildar@tatar.ru |
| Актаныш | Хәкимов Илдус Маһиҗан улы | Ildus.Hackimov@tatar.ru |
| Алексеевск | Бакиров Фәнис Галимҗан улы | Fanis.Backirov@tatar.ru |
| Әлки | Петухов Андрей Николаевич | Petuhov.Andrey@tatar.ru |
| Әлмәт | Закиров Рамил Миннеәхмәт улы | Zakirov.R@tatar.ru |
| Апас | Солтанбәков Ирек Фатыйх улы | Irek.Sultanbekov@tatar.ru |
| Арча | Касыймов Габделхак Габделфәрт улы | Gabdelhak.Kasimov@tatar.ru |
| Баулы | Талипов Альберт Мәгъсүм улы | Albert.Talipov@tatar.ru |
| Әтнә | Сабиров Рафил Камил улы | Rafil.Sabirov@tatar.ru |
| Балтач | Габдрахманов Марат Ренат улы | Gabdrahmanov.Marat@tatar.ru |
| Бөгелмә | Попов Сергей Александрович | Popov.Sergey@tatar.ru |
| Буа | Разбитнов Евгений Григорьевич | E.Razbitnov@tatar.ru |
| Югары Ослан | Сибгатуллин Дмитрий Ринат улы | Dmitriy.Sibgatullin@tatar.ru |
| Биектау | Гарипов Рәшит Әнвәр улы | Garipov.Rashit@tatar.ru |
| Чүпрәле | Шәйхатдаров Илдар Иршат улы | Ildar.Shayhatdarov@tatar.ru |
| Алабуга | Шияпов Марсель Минемөнавир улы | Marsel.Shiyapov@tatar.ru |
| Зәй | Гончаров Валентин Григорьевич | Valentin.Goncharov@tatar.ru |
| Зеленодольск | Мөхәммәтҗанов Мансур Мөнир улы | Mansur.Muhametzyanov@tatar.ru |
| Кама Тамагы | Гайнуллин Хәмит Мирхатыйп улы | Hamit.Gaynullin@tatar.ru |
| Кайбыч | Серебряков Михаил | Mihail.Serebryakov@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| | Николаевич | |
| Кукмара | Вәлиев Алмаз Хәбир улы | Almaz.Valiev@tatar.ru |
| Лаеш | Гәрәев Радик Әнвәр улы | Radik.Garaev@tatar.ru |
| Лениногорск | Галимов Илнур Наил улы | Ilnur.Galimov@tatar.ru |
| Мамадыш | Сафин Илнур Рафаэл улы | Safin.Ilnur@tatar.ru |
| Менделеевск | Насыйбуллин Раушан Рафаил улы | Raushan.Nasibullin@tatar.ru |
| Минзәлә | Гыйльманов Ринат Максут улы | Rinat.Gilmanov@tatar.ru |
| Мөслим | Шәрәфетдинов Рамил Ралиф улы | Ramil.Zarafutdinov@tatar.ru |
| Түбән Кама | Мөниров Рәмзин Рафис улы | Ramzin.Munirov@tatar.ru |
| Яңа Чишмә | Хисмәтуллин Рәис Ваһап улы | Rais.Hismatullin@tatar.ru |
| Нурлат | Кудряшов Дмитрий Юрьевич | Dmitriy.Kudryashov@tatar.ru |
| Питрәч | Максимов Валерий Васильевич | Valerii.Maksimov@tatar.ru |
| Балык Бистәсе | Гыймаев Линар Кыяметдин улы | Linar.Gimaev@tatar.ru |
| Саба | Харисов Рөстәм Раиф улы | Rustem.Harisov@tatar.ru |
| Сарман | Сәлахов Альберт Расыйх улы | Albert.Salakhov@tatar.ru |
| Спас | Батыршин Илнур Фазыл улы | Ilnur.Batyrshin@tatar.ru |
| Тәтеш | Балантаев Сергей Анатольевич | Sergey.Balantaev@tatar.ru |
| Тукай | Әхмәтшин Марат Ринат улы | Marat.Ahmetshin@tatar.ru |
| Теләче | Нәзиров Хәмит Хаҗип улы | Hamit.Nazirov@tatar.ru |
| Чирмешән | Сәлахов Илнур Тәлгат улы | Ilnur.Salahov@tatar.ru |
| Чистай | Дудин Сергей Михайлович | Sergey.Dudin@tatar.ru |
| Ютазы | Рәкыйпов Назыйм Нәсим улы | Nazim.Rakipov@tatar.ru |
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| Казан | Әхмәтҗанов Марат Ренат улы | Ahmetzyanov.Marat@tatar.ru |